**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт граждан хезмәте турында федераль законнарның үзгәрүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре департаментына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәне кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасы кадрлар резервына яисә Татарстан Республикасы дәүләт органнары кадрлар резервына кертелгән затларның реестры формасын расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2013 ел, 25 декабрь
№ ПУ-1270

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның «25» декабрендәге
ПУ-1270 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервын формалаштыруның, аның белән эшләүне оештыруның һәм аны Татарстан Республикасы дәүләт органнарында (алга таба – дәүләт органнары) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең (алга таба – дәүләт хезмәте) вакантлы вазыйфаларын биләү өчен файдалануның тәртибен билгели.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы дигәндә, Татарстан Республикасы кадрлар резервы һәм дәүләт органнары кадрлар резервлары аңлашыла.

3. Татарстан Республикасы кадрлар резервына кертелгән затлар реестры Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (алга таба – Департамент) тарафыннан алып барыла.

Дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән затлар реестры дәүләт органының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе (алга таба – дәүләт органының кадрлар хезмәте) тарафыннан алып барыла.

Татарстан Республикасы кадрлар резервына яисә дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән затлар реестры Департамент тарафыннан раслана торган форма буенча алып барыла.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервын формалаштыруның төп максаты булып дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын югары квалификацияле белгечләр тарафыннан оператив биләү мөмкинлеген тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) хезмәт буенча үсүе процессының максималь нәтиҗәлелегенә ирешү тора.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы формалаштыруның төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

дәүләт хезмәткәрләренең һәм дәүләт хезмәткәрләре булмаган Россия Федерациясе гражданнарының (алга таба – гражданнар) дәүләт органы кадрлар резервына керү өчен конкурста катнашу мөмкинлекләренең тигезлеге;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертүгә кандидатларның һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервына кертелгән затларның һөнәри һәм башка сыйфатларын бәяләүнең объективлыгы;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелүнең ихтыярилыгы.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервында булу вакыты 3 ел тәшкил итә.

7. Дәүләт хезмәткәре (граждан) берничә дәүләт органында кадрлар резервында тора ала.

## II. Дәүләт органы кадрлар резервын формалаштыру

8. Дәүләт органы кадрлар резервы тиешле яллаучы вәкиле тарафыннан формалаштырыла.

9. Дәүләт органына кадрлар резервына кертү түбәндәгечә башкарыла:

а) гражданнарны – дәүләт органы кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча;

б) гражданнарны – дәүләт органында дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча, күрсәтелгән гражданнар ризалыгы белән;

в) вазыйфаи үсеш тәртибе буенча дәүләт органында дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен дәүләт хезмәткәрләрен – дәүләт органы кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча;

г) вазыйфаи үсеш тәртибе буенча дәүләт органында дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен дәүләт хезмәткәрләрен – дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча, күрсәтелгән дәүләт хезмәткәрләре ризалыгы белән;

д) вазыйфаи үсеш тәртибе буенча дәүләт органында дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен дәүләт хезмәткәрләрен – «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 48 статьясындагы 16 өлешенең 1 пунктында каралган аттестация нәтиҗәләре буенча, күрсәтелгән дәүләт хезмәткәрләре ризалыгы белән;

е) Федераль законның 37 статьясындагы 1 өлешенең $8^2$ пункты нигезендә дәүләт хезмәте вазыйфасының кыскартылуы йә Федераль законның 37 статьясындагы 1 өлешенең $8^3$ пункты нигезендә дәүләт органы бетерелү белән бәйле рәвештә дәүләт хезмәтеннән азат ителүче дәүләт хезмәткәрләрен – дәүләт хезмәте вазыйфалары кыскартылучы дәүләт органының яисә бетерелгән дәүләт органы функцияләре тапшырылган дәүләт органының яллаучы вәкиле карары буенча, күрсәтелгән дәүләт хезмәткәрләре ризалыгы белән;

ж) Федераль законның 39 статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләр буенча дәүләт хезмәтеннән азат ителүче дәүләт хезмәткәрләрен, күрсәтелгән дәүләт хезмәткәрләре ризалыгы белән.

10. Дәүләт хезмәткәрләрен (гражданнарны) дәүләт органының кадрлар резервына кертү алар билгеләп куелырга мөмкин булган дәүләт хезмәте вазыйфалары төркемен күрсәтеп гамәлгә ашырыла. Моннан тыш, дәүләт хезмәткәрләре (гражданнар) биләү өчен дәүләт органы кадрлар резервына кертелә торган структур бүлекчәнең атамасы өстәмә рәвештә күрсәтелергә мөмкин.

Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «е» һәм «ж» пунктчалары нигезендә дәүләт хезмәткәрләрен дәүләт органының кадрлар резервына кертү дәүләт хезмәткәре тарафыннан соңгы биләнгән вазыйфасына кертелүче граждан хезмәтенең шул ук төркеме дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен башкарыла.

11. Дәүләт хезмәткәрен (гражданны) дәүләт органы кадрлар резервына кертү һәм аннан чыгару дәүләт органы хокукый акты белән рәсмиләштерелә һәм нигезләр барлыкка килгән көннән соң өч эш көнендә башкарыла.

Дәүләт хезмәткәрен дәүләт органы кадрлар резервына керткәндә һәм аннан чыгарганда аның шәхси эшенә бу турыда тиешенчә теркәп куела.

12. Дәүләт органы кадрлар резервына башка дәүләт органында дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәре кертелгән очракта, дәүләт органының хокукый акты күчермәсе кабул ителгән көннән җиде эш көнендә тиешле дәүләт органына җибәрелә.

13. Дәүләт органы хокукый акты нигезендә аны кабул иткәннән соң өч эш көнендә дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән затлар реестрында тиешенчә теркәп куела.

Дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән затлар реестрына тиешле үзгәрешләр турындагы белешмәләр шуңа нигез барлыкка килгән көннән соң җиде эш көнендә дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан Департаментка җибәрелә.

14. Дәүләт органы кадрлар резервына кертүгә конкурс дәүләт органы кадрлар хезмәте тарафыннан дәүләт органы дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен белгечләргә ихтыяҗ туу ихтималын һәм дәүләт органының гамәлдәге кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

15. Дәүләт органы кадрлар резервына ихтыяҗ ихтималын бәяләгәндә түбәндәгеләр исәпкә алына:

дәүләт органының кадрлар белән комплектланганлыгы;

дәүләт органының кадрлар резервы белән тәэмин ителеше;

дәүләт органында дәүләт хезмәтендә вакантлы вазыйфалар барлыкка килү ихтималы;

дәүләт органының кадрлар резервыннан чыгаруны фаразлау.

16. Дәүләт органы кадрлар резервына кертүгә конкурс дәүләт органының конкурс комиссиясе тарафыннан федераль законнар белән дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс өчен билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

## III. Татарстан Республикасы кадрлар резервын формалаштыру

17. Татарстан Республикасы кадрлар резервы дигәндә, Татарстан Республикасы дәүләт органнарының бердәм кадрлар резервы аңлашыла.

18. Татарстан Республикасы кадрлар резервы Департамент тарафыннан дәүләт хезмәтенең югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен дәүләт органнарының кадрлар резервларына кертелгән дәүләт хезмәткәрләреннән (гражданнарыннан) формалаштырыла.

19. Татарстан Республикасы кадрлар резервына дәүләт хезмәткәрен (гражданны) кертү һәм аннан чыгару Департаментның хокукый акты белән рәсмиләштерелә һәм Департамент тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында каралган белешмәләр алынган көннән соң җиде эш көнендә тормышка ашырыла.

## IV. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы белән эшләү

20. Дәүләт органы кадрлар резервы белән эшләү тиешле дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан әлеге дәүләт органының кадрлар резервына кертелгән затларны әзерләүнең индивидуаль планнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Индивидуаль планнар дәүләт органының кадрлар резервына кертелгән затлар катнашында дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан эшләнә һәм тиешле дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан раслана.

21. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар резервы белән эшләүгә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервына кертелгән затларга квалификацияләрен күтәрү, яңадан һөнәри әзерләү программалары буенча өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру керә.

22. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән затларга өстәмә һөнәри белем бирү өстәмә һөнәри программалар буенча мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда башкарыла.

23. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы белән эшләү өчен кирәкле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджетында бу максатларга каралган акчалар исәбеннән башкарыла.

## V. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервыннан файдалану

24. Татарстан Республикасы дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән затлар дәүләт органында дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасына тиешле эшкә яллаучы вәкиле карары буенча билгеләп куела.

25. Дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп кую дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасы кирә торган шул ук төркемнең дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән затлар арасыннан күрсәтелгән затлар ризалыгы буенча башкарыла.

26. Дәүләт хезмәтенең тиешле вазыйфалар төркемендә вакантлы вазыйфасын биләү өчен дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламент таләпләренә җавап бирүче берничә зат торган очракта, яллаучы вәкиле мөстәкыйль рәвештә аларның берсен сайлап ала.

Сайлап алу әңгәмә нәтиҗәләре буенча башкарыла, аның барышында вакантлы вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы затның әлеге вазыйфа буенча һөнәри хезмәт бурычларын үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе (социаль адаптация дәрәҗәсе, интеллектуаль дәрәҗәсе, психологик тотрыклылыгы, коммуникатив сыйфатлары) билгеләнә.

27. Дәүләт хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән дәүләт хезмәткәрен (гражданны) дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп кую турында карар кабул ителгәннән соң, яллаучы вәкиле күрсәтелгән затка дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү турында язма рәвештә тәкъдим җибәрә. Күрсәтелгән язмача тәкъдимне тиешле дәүләт хезмәткәре (граждан) шәхсән кул куеп ала яисә аңа тапшырылуы турында хәбәр белән заказлы хат рәвешендә, йә адресатның язмача тәкъдимне алу вакытын күрсәтүне тәэмин итүче элемтә һәм тапшыруның башка чараларын файдаланып җибәрелә.

Дәүләт органының кадрлар резервына кертелгән дәүләт хезмәткәре (граждан) дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү турында тәкъдим алган көннән соң 10 эш көне дәвамында яллаучы вәкиле адресына дәүләт хезмәтенең тиешле вазыйфасына билгеләп кую турында язмача гариза яки дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүдән баш тарту турында язмача хәбәр җибәрә.

Дәүләт органының кадрлар резервына кертелгән дәүләт хезмәткәренең (гражданның) билгеләнгән вакытта җавап бирмәве тәкъдим ителгән дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүдән баш тартуы дип танылa.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән дәүләт хезмәткәренең (гражданның) дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүдән баш тартуы турында мәгълүматлар дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән затлар реестры һәм Татарстан Республикасы кадрлар резервына кертелгән затлар реестрында исәпкә алына.

28. Татарстан Республикасы кадрлар резервына кертелгән дәүләт хезмәткәре (гражданнар) арасыннан сайлап алынган затлар түбәндәге очракларда дәүләт органында дәүләт хезмәте вакантлы вазыйфасын били:

а) дәүләт хезмәтенең тиешле вазыйфалар төркемендә вакантлы вазыйфасын биләү өчен дәүләт органы кадрлар резервына кертелгән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламент таләпләренә җавап бирүче

затларның дәүләт органында дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүдән баш тартканда;

б) дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасы караган төркем дәүләт хезмәте вазыйфасын биләү өчен дәүләт органының кадрлар резервы булмаганда.

29. Дәүләт органында дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасы караган шул ук төркем вазыйфаларын биләү өчен Татарстан Республикасы кадрлар резервына кертелгән дәүләт хезмәткәрләре (гражданнары) турында белешмәләрне алу өчен дәүләт органы җитәкчесе Департаментка, дәүләт органының структур бүлекчәсен һәм дәүләт хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча квалификацион таләпләрне күрсәтеп, дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасы турындагы мәгълүматы булган сорату җибәрә.

Әлеге соратуны алганнан соң җиде эш көнендә Департамент дәүләт органында дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасы кертелгән шул ук төркем дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Татарстан Республикасы кадрлар резервына кертелгән дәүләт хезмәткәрләре (гражданнар) турындагы белешмәләрне җибәрә.

30. Татарстан Республикасы кадрлар резервына кертелгән затны дәүләт органында дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп кую әлеге Нигезләмәнең 24-27 пунктлары билгеләгән тәртиптә тормышка ашырыла.

31. Татарстан Республикасы кадрлар резервына кертелгән зат дәүләт органындагы дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп куелудан баш тарткан йә дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасы керә торган шул ук төркем буенча дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Татарстан Республикасы кадрлар резервы булмаган очракта, дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү Федераль законның 22 статьясында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

## VI. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервыннан чыгару

32. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән зат аннан түбәндәге нигезләр буенча чыгарыла:

а) аны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервыннан дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп кую;

б) аның дәүләт органы кадрлар резервында тору срогы тәмамлануы;

в) дәүләт органы кадрлар резервыннан төшереп калдыру турында күрсәтелгән затның язмача гаризасы;

г) күрсәтелгән затның дәүләт хезмәте узуына киртә булырлык хәлләрнең булуы яисә ачыклануы;

д) күрсәтелгән зат билгеләп куелырга мөмкин булган дәүләт хезмәте вазыйфасы төркеменнән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүгә тәкъдим итүдән кабат баш тартуы;

е) күрсәтелгән затның үлеме (вафаты), законлы көченә кергән суд карары белән аның хәбәрсез югалган дип танылуы яисә үлгән дип игълан ителүе;

ж) әгәр дә шундый үзгәреш нәтиҗәсендә дәүләт хезмәткәре (граждан) аларга туры килми башласа, күрсәтелгән зат билгеләп куелырга мөмкин булган дәүләт хезмәте вазыйфаларына квалификация таләпләренең үзгәрүе;

з) Федераль законның 48 статьясындагы 16 өлешенең 3 пункты нигезендә аны аттестацияләү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән дәүләт органы кадрлар резервыннан дәүләт хезмәткәрен төшереп калдыру турында яллаучы вәкиленең карары;

и) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы беренче өлешнең 5-11 пунктлары нигезендә граждан белән хезмәт шартнамәсен өзү;

к) Федераль законның 37 статьясындагы 1 өлешенең $8^2$, $8^3$ пунктларыннан тыш, Федераль законның 37 статьясының 1 өлешендә каралган нигезләр буенча хезмәт контрактын өзү һәм дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәтеннән азат итү.

33. Әлеге Нигезләмәнең 32 пунктындагы «е» һәм «к» пунктчаларында каралган очракларда, дәүләт хезмәткәре дәүләт хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органы нигезләр барлыкка килгән көннән соң җиде эш көнендә ул кадрлар резервына кертелгән дәүләт органнарына тиешле мәгълүмат җибәрә.

---